Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
“3 нче гимназия”муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе

Дәрестән тыш эшчәнлек буенча авторлык программасы

# « Сәхнә йолдызлары»

автор-төзүче: 1 нче квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Шәрифуллина Гөлия Әзгать кызы

2020

## Аңлатма язуы

Театр-ул төрле сәләтләрне үз эченә алган тылсымлы сәнгать дөньясы. Шуңа күрә, бу сәләтләрне үстерү белән генә чикләнмичә, балаларда яшьтән театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү мөһим.

Театр эшчәнлеге балада әдәбиятка, сәнгатькә карата кызыксыну уята. Балаларның тормышы кызыклырак,эчтәлеклерәк була бара. Иҗат шатлыгын тою аларны куандыра.Дөрес юнәлеш биргәндә, балада артист, режиссёр, театр рәссамы, дирижёр хезмәте турында күзаллау формалаша. Аның танып-белү эшчәнлеге ныгый. Бала берникадәр вакытка герой булып тора, үз-үзенә бәя бирә, үз гомерендә беренче кул чабуларны ишетә.

Театр – коллектив хезмәт. Спектакль – коллективның иҗади тырышлыгы нәтиҗәсе.Театр дәресләре балаларда бердәмлек,чын дуслыкның кадерен белү, үз-үзеңә һәм башкаларга карата таләпчәнлек тәрбияли.

Театр, сәнгать буларак, тормышта һәм кешеләрдә гүзәллекне күрергә өйрәтә, үзеңә изге һәм игелекле тормыш алып барырга омтылыш тудыра. Программаны тормышка ашыру, интонация, мимика, жест, пластик кебек театраль сәнгать чаралары ярдәмендә, билгеле бер әдәби әсәрләрнең эчтәлеге белән таныштырып кына калмыйча, балаларны конкрет образлар тудырырга, әлеге әсәр геройлары арасындагы мөнәсәбәтләрне тирән хис итәргә дә өйрәтә. Театраль уен мәктәп укучысы тормышында балалар фантазиясен, күзаллауларын, хәтерен, балалар иҗатының барлык төрләрен (нәфис-сөйләм, музыкаль-уен, бию, сәхнә) үстерүгә ярдәм итә. Бер үк вакытта сыйныф коллективының берләшүенә, укучыларның һәм укытучыларның мәдәни диапазонын киңәйтүгә, үз-үзеңне тоту культурасын арттыруга ярдәм итә.        Театр сәнгате үзенең күпкырлы булуы, күплеге һәм синтетик табигате белән балага дөнья чыгу кысаларын аерырга ярдәм итә ала. Аның игелеге, үз фикерләре белән уртаклашу, башкаларны ишетү теләге белән мавыгу, үсү, иҗат итү һәм уйнау. Чөнки нәкъ менә уен театр сәнгатенең алыштыргысыз атрибуты бар, һәм шул ук вакытта уен барлыкка килгән очракта балалар һәм педагоглар максималь уңай нәтиҗә алып үзара хезмәттәшлек итәләр.

Программа баланың шәхесен үстерүгә, аның шәхси һәм метапредмет нәтиҗәләренә карата таләпләргә юнәлдерелгән, ул балалар белән тәрбия-белем бирү эшен гуманлаштыруга юнәлтелгән, мәктәп укучыларын үстерүнең психологик үзенчәлекләренә нигезләнгән.

Әлеге программа укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатын күздә тотып төзелде. Түгәрәк эше шулай ук сәхнә

серләренә төшенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Укучыларда лингвистик (тел), аралашу (коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру рус мәктәбендә татар теленә өйрәтүнең максатын тәшкил итә. Әлеге компетенцияләрне булдыру өчен , дәрестән тыш эшләрне файдалану аеруча әһәмиятле.Белем һәм тәрбия бирү бер-берсеннән аерылгысыз. Дәресләрдә алган белемнәрне мәктәптәге түгәрәкләрдә, факультатив дәресләрдә,электив курсларда камилләштерү, тулыландыру һәм ныгыту бүген көнүзәк мәсьәләләрнең берсе.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының сөйләм телен үстерү дәрестән тыш оештырылган эшләр аша алып барыла. Рус мохитендә яшәгән татар балаларын чиста, төзек әдәби телдә сөйләшергә өйрәтү, татар сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, китап укуга кызыксыну уяту, үзләрендә язу теләге уяту максатыннан түгәрәкләр оештырыла.

**Программаның юнәлеше.** Программа дәрестән тыш эшчәнлектә гомуми мәдәни (сәнгать-эстетик) юнәлешне тормышка ашыра.

**Программаның актуальлеге.** Белем бирү программасының яңалыгы шунда ки, укыту-тәрбия процессы төрле эш юнәлешләре аша башкарыла: тамашачылар мәдәнияте нигезләрен тәрбияләү, башкару эшчәнлеге күнекмәләрен үстерү, театр турында белемнәр туплау.Болар һәммәсе бер-берсе белән үрелеп, бер-берсен тулыландырып, үсеп килүче буында әхлакый сыйфатлар формалаштыруга нигез булып тора.

Алынган белемнәр балаларга психологик инертлыкны җиңәргә, аларның иҗади активлыгын арттырырга, чагыштыра, анализлый, планлаштыра белергә, эчке максатлар куярга, аларга омтылырга мөмкинлек бирәчәк.

**Программаның максатлары:**

а) укучыларда Татарстан Республикасында театр сәнгате үсеше турында күзаллау формалаштыру;
б) балаларның сәнгати һәм эстетик культурасын үстерү,аларга тормышта яхшылык һәм матурлыкны күрергә өйрәтү;
в) укучыларда милли үзаң, иҗадилек тәрбияләү, театр сәнгатенә һәм актерлык эшчәнлегенә карата кызыксыну уяту
г) Татарстандагы барлык күпмилләтле театр коллективлары иҗатындагы милли мәдәният кыйммәтләренә карата горурлык һәм хөрмәт хисләре формалаштыру.

**Бурычлар:**

-театрның үткәне һәм бүгенгесе белән таныштыру;

-театрга нигез салучыларның иҗади эшчәнлегенә күзәтү ясау;

-балаларны театрның төрле төрләре белән таныштыру (курчак, драма, опера, балет театры, музыкаль комедия);

-драма әсәрләрен өйрәнүгә теләк уяту;

-төрле жанрдагы әсәрләрне сәхнәгә кую аша укучыларның табигатьтән бирелгән сәләтләрен үстерү;

-образны кичерү һәм гамәлгә ашыру планында балаларның артистлык күнекмәләрен камилләштерү, бирелгән шартларда социаль үз-үзеңне тоту күнекмәләрен модельләштерү;

-сәхнәдә үзеңне тоту осталыгын, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен өйрәнү һәм камилләштерү;

-укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү;

-чыгыш ясау, аралашуга өйрәтү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү .

**Түгәрәк эше буенча көтелгән нәтиҗәләр :**

-укучы үзен иркен тотарга өйрәнә, психологик яктан ачыла;

-үзенең мавыгуына туры килгән эш белән шөгыльләнә;

-түгәрәктәге башка укучылар, укытучы белән аралашу вакытында эчке дөньясында ачыла, аралашу әдәбенә өйрәнә;

-укучы фикерләргә, үз фикерен дәлилләргә өйрәнә;

-сөйләм телен камилләштерә ;

-әхлак һәм зәвык тәрбиясе ала;

-шәхес булып тәрбияләнә, үз урынын таба;

-татар теле һәм әдәбияты буенча белемен тирәнәйтә, кызыксыну уята.

Түгәрәк татар теле һәм әдәбияты программасын кабатларга тиеш түгел.Түгәрәкнең эш формасы күп төрле, монда укытучының иҗади сәләте зур роль уйный. Китап уку, аның турында фикер алышу, кечкенә докладлар төзү, язучы иҗатын өйрәнү, укылган китап буенча киносценарийлар төзү, шигырь укучылар бәйгеләре оештыру, әдәби -музыкаль монтаж әзерләү, музейларга бару, җирле матбугат белән танышу, рецензия язарга өйрәнү, һ.б. бик күп төрле эш алымнары бар. Түгәрәкләрдә техник чаралар да куллану кирәк, эш барышында музыка яңгырату, магнитофон, телевизор, компьютер куллану эшне тагын да җанландыра.

Түгәрәк эше балаларның күзаллавын киңәйтергә, аңа яңалык алып килергә, рухи тәрбия бирергә дә тиеш. Халык авыз иҗатын, татар халык педагогикасын куллану, табигать белән аралашу түгәрәк эшләрен оештырганда укытучыга зур мөмкинлекләр ача.

**Эш формалары.** Дәресләрне үткәрүнең төп формалары булып тора:

-театр уеннары,

-конкурслар,

-викториналар,

-әңгәмә,

-театр һәм музейларга экскурсияләр,

-спектакльләр,

-бәйрәм.

Бәйрәмнәрдә сценарийларны сәхнәләштерү, экиятләр, әдәби әсәрләрдән өзекләр кую - болар барысы да балаларны театр сәнгатенә һәм осталыгына җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

**Көтелгән нәтиҗәләр (ФГОС нигезендә)**: программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә укучыларда УУГ оештырылачак.

Шәхси нәтиҗәләр:

• яшьтәшләренә карата уңай мөнәсәбәт һәм хезмәттәшлек итүгә ихтыяҗ;

• матур әдәбият әсәрләрен уку һәм өйрәнү нәтиҗәсендә этик хисләр, эстетик ихтыяҗлар, кыйммәтләр;

• шәхси үсеш өчен театр эшчәнлеге белән шөгыльләнүнең әһәмиятлелеген аңлау.

Метапредмет нәтиҗәләр.

Регулятив УУГ:

-җитәкче формалаштырган бурычны аңлау һәм кабул итү;

-әсәр өстендә эшләүнең аерым этапларында үз гамәлләреңне планлаштыра алу;

-үз эшчәнлегеңне контрольдә тота, төзәтә һәм бәяли алу;

-уңыш һәм уңышсызлыкның сәбәпләрен анализлый алу, укытучы ярдәмендә позитив фикер йөртергә өйрәнә алу.

Танып-белү УУГ:

- биремнәрне үтәгәндә алынган мәгълүматны аңлау һәм куллану;

-уеннарда, этюдларны сәхнәләштерүдә, рольләрне уку барышында индивидуаль иҗади сәләтләрен күрсәтү.

Коммуникатив УУГ:

- диалогка, күмәк фикер алышуга кушылу,активлык һәм инициатива күрсәтү;

-төркемдә эшли белү,башкаларның фикерен тыңлый белергә өйрәнү;
-ярдәм сорап мөрәҗәгать итә  белү;
-ярдәм һәм хезмәттәшлек тәкъдим итә белү;
-әңгәмәдәшеңне тыңлый белү;
-күмәк эшчәнлектә функцияләрнең бүленеше турында уртак фикергә килә алу;
-үз фикереңне һәм позицияңне формалаштыру;
-үз-үзеңнең һәм тирә-юньдәгеләрнең тотышын адекват бәяли белү.

**Программаны тормышка ашыру шартлары.**

-Программа 1 елга, 35 сәгатькә төзелгән.
-Түгәрәктәге балалар саны 15 кешедән дә ким түгел.
-Балаларның яше: 12-14 яшьлекләр.
Әлеге программаны тормышка ашыру өчен билгеле бер эш шартлары кирәк: театр костюмнары, реквизит, декорация элементларын куллану мөмкинлеге,спектакль өчен сәхнә мәйданчыгы, репетицияләр залы, яктылык, музыкаль бизәлеш аппаратурасы, театр костюмнары, грим, париклар.

**Программа эчтәлеге**

| **№** | **Бүлекләр** | **Сәгать саны** |
|---|---|---|
| 1. | Театр тарихыннан | 4 |
| 2. | Казандагы театрлар | 4 |
| 3. | Күренекле драматурглар  һәм балалар сәхнәсе | 8 |
| 4. | Актерлык эшчәнлеге | 8 |
| 5. | Сәхнә сәнгате | 8 |
| 6. | Театрның роле һәм үсеше | 3 |
| | Барлыгы: | 35 |

Театр укучыларны тәрбияләүдә һәм белем бирүдә аерым роль уйный. Театр әсәре аша бала тормышы, аның авыр һәм кайвакыт хәл ителә торган проблемалары белән таныша. Ел дәвамында эш төрле юнәлешләрдә алып барыла.

**“Театр тарихыннан”**. Бу юнәлеш театр тарихын, театр сәнгатенең үзенчәлекләрен өйрәнүне,артистлар белән танышуны күздә тота. Бу өстәмә материал укучыларның белемнәрен баетырга, театр тарихын, аның кешеләр тормышында әһәмиятен аңларга ярдәм итәчәк.

**“Казандагы театрлар”.** Әлеге өлештә төрле театрлар белән таныштырыла, кызыклы һәм кирәкле мәгълүматлар бирелә.

**“Күренекле драматурглар  һәм балалар сәхнәсе**”. Театрны драматурглардан башка күз алдына китерү бик авыр. Бу  бүлектә драматурглар,балалар өчен язылган сәхнә әсәрләре турында сөйләнәчәк .

**“Актерлык эшчәнлеге”.** Бу юнәлештә образларны күзәтеп, дөрес итеп сурәтли белү, театр куелышларын, актерларның уенын күзәтү эше алып барыла.

**“Сәхнә сәнгате”.**  Элеге юнәлеш күбрәк практик өлешне күзаллый. Театрның җыр һәм бию белән үрелешен күрсәтә, сәхнә әсәре өстендә эшләүне күз алдында тота.

**“Театрның роле һәм үсеше”.** Биредә укучылар театрның әһәмияте, аның кешеләр тормышында урыны белән танышалар.

**Тематик планлаштыру**

| № | Тема | Сәг.саны | Теория | Практика | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | план | факт |
| | | | **Театр тарихыннан– 4сәг.** | | | |
| 1. | Кереш дәрес. Театр сәнгатенең үзенчәлекләре. | 1 | 1 | | | |
| 2. | Театр тарихы. | 1 | 1 | | | |
| 3. | Беренче артистлар. | 1 | 1 | | | |
| 4. | Бүгенге көн артистлары. | 1 | 1 | | | |
| | | | **Казандагы театрлар – 4 сәг.** | | | |
| 5. | Г.Камал театры. | 1 | 1 | | | |
| 6. | К.Тинчурин театры. | 1 | 1 | | | |
| 7. | Әкият курчак театры. | 1 | 1 | | | |
| 8. | Яшь тамашачылар театры. | 1 | 1 | | | |
| | | | **Күренекле драматурглар  һәм балалар сәхнәсе – 8 сәг.** | | | |
| 9. | Г.Камал һәм К.Тинчурин иҗатлары. | 1 | 1 | | | |
| 10. | Аманулла иҗаты. | 1 | 1 | | | |
| 11. | Т.Миңнуллин иҗаты. | 1 | 1 | | | |
| 12. | Г.Гыйльманов иҗаты. | 1 | 1 | | | |
| 13. | Р.Вәлиеваның сәхнә әсәрләре. | 1 | 1 | | | |
| 14. | Балалар өчен яылган сәхнә әсәрләрендә кызыклы персонажлар. | 1 | 1 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 15. | Сәхнәгә кую өчен пьеса сайлау, сценарий өстендә эш. | 1 | | 1 | | |
| 16. | Сценарий структурасы белән танышу. Рольләр өстендә эшләү. | 1 | | 1 | | |
| **Актерлык эшчәнлеге – 8 сәг.** | | | | | | |
| 17. | Театр структурасы, төп һөнәрләр белән танышу: актер, режиссер, сценарист, художник, гример. | 1 | 1 | | | |
| 18. | Грим салу техникасы. | 1 | | 1 | | |
| 19. | Актерлык осталыгы. Спектакль өстендә эш (репетиция). | 1 | | 1 | | |
| 20. | Образ өстендә эшләү.Репетиция. | 1 | | 1 | | |
| 21. | Мимика өстендә эшләү. | 1 | | 1 | | |
| 22. | Сәхнә сөйләме. Дикция. | 1 | | 1 | | |
| 23. | Авазлар әйтелеше. Артикуляцион гимнастика. | 1 | | 1 | | |
| 24. | Персонажларның үз-үзләрен сәхнәдә тоту үзенчәлекләре. | 1 | | 1 | | |
| **Сәхнә сәнгате – 8 сәг.** | | | | | | |
| 25. | Сәхнә сәнгатенә кызыксыну уяту. Спектакль өстендә эш (репетиция). | 1 | | 1 | | |
| 26. | Театраль костюмнар. | 1 | 1 | | | |
| 27. | Биюләр һәм роль. | 1 | | 1 | | |
| 28. | Пьсаның музыкаль бизәлеше. | 1 | | 1 | | |
| 29. | Рольләрне биюләр белән тулыландыру. | 1 | | 1 | | |
| 30. | Пьесада музыка һәм җырлар. | 1 | | 1 | | |
| 31. | Спектакль өстендә эш (репетиция). | 1 | | 1 | | |
| 32. | Спектакльне сәхнәгә кую. | 1 | | 1 | | |
| **Театрның роле һәм үсеше -3 сәг.** | | | | | | |
| 33. | Театр кичә, бүген, иртәгә... | 1 | 1 | | | |
| 34. | Кеше тормышында театрның роле. | 1 | 1 | | | |
| 35. | Йомгаклау. Еллык эшкә нәтиҗә ясау. | 1 | 1 | | | |

**Кулланылган әдәбият**

1.Гыйльманов Г.. Көмеш тарак: пьесалар, шигырьләр.-Казан:Татар.кит.нәшр.,2000.

2. Закирҗанов Ә.М.Хәзерге татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләре: Уку-укыту әсбабы. - Казан: Казан ун-ты нәшр., 2010.

3. Минһаҗева Л.И., Мияссарова И.Х. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия.- Казан: ТР “Хәтер” нәшр.,2011.

4.Низамова Р. Гомерлек сабак. - Казан: 2008.

5.Электрон ресурслар:

https://tt.wikipedia.org/wiki/Татар_драматурглары

http://magarif-uku.ru/drama-tugerege-tormyshka-ezerli/